**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

19" ноябрь 2023 ел — № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш, хәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Кече Әтнә авылының Совет, К. Маркс һәм Тукай урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар ,куаклар, үсентеләр кисү, каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр алып китү);

2) Кече Әтнә авылы торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, капламаларны ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү);

3) Спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау.

4) Кече Әтнә авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү;

3. 2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән спорт мәйданчыгы төзү өчен 27000 сум күләмендә гражданнарның кулланылмаган үзара салымы акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) Спорт мәйданчыгы төзү һәм балалар мәйданчыгын ремонтлау

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Кече Әтнә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: — Порфирьев С.Н.